ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Емельянов Геннадий Егоровичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында

«Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты статусы турында» 2004 елның 18 мартындагы 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 пунктының «а» пунктчасы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

37 нче Алабуга бермандатлы сайлау округыннан сайланган Емельянов Геннадий Егоровичның Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты вәкаләтләрен, аның Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Федерация Советы әгъзасы – Татарстан Республикасы Дәүләт Советыннан вәкил вәкаләтләренә ия булуга бәйле рәвештә депутат вәкаләтләрен туктатуы турындагы язма гаризасы нигезендә, 2019 елның 1 октябреннән вакытыннан алда туктатылган дип санарга.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2019 елның 25 сентябре
№ 91-VI ДС